| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ БЕЛӘН И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.12.2016 № 737

г.Казань

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 25 гыйнварында теркәлде, № 3802

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге “Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнарны компенсацияләү юлы белән, ана (гаилә) капиталы акчасын (акчаның бер өлешен) андый товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга юллау кагыйдәләре турында” № 380 карарын, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 16 июнендәге “Гражданнарның ана (гаилә) капиталы акчасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасына туры китереп, инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга файдалану хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү буенча эшне оештыру турында” № 296 боерыгын һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 4 октябрендәге “Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын гражданнарга бирү тәртибе турында” № 568 боерыгын гамәлгә ашыру кысасында боерык бирәм:

1. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелүче административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль

районнарындагы (шәһәр округларындагы) идарәләре (бүлекләре) начальникларына: регламент нигезләмәләренең үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының инвалидлар белән эшләү бүлеге һәм социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге эшчәнлеге өчен җаваплы урынбасарларына йөкләргә.

**Министр** **Э.Ә. Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 26 декабрендәге № 737 боерыгы белән расланды

**Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең бу административ регламенты (алга таба – Регламент) инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте алучы булып ана (гаилә) капиталына сертификатның хуҗасы (алга таба – дәүләт хезмәте алучы) тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүчеләр (алга таба – гариза бирүче) булып дәүләт хезмәте алучы яки аның законлы вәкиле яисә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә дәүләт хезмәте алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән зат тора.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлек) тарафыннан, ана (гаилә) капиталына сертификатның хуҗасының яшәү яки вакытлыча тору урынында күрсәтелә.

1.4.1. Идарәнең (бүлекнең) урнашу урыны, белешмәләр алу өчен телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат бу Регламентка белешмә-кушымтада китерелгән.

Идарәнең (бүлекнең) эш графигы: Идарәнең (бүлекнең) эчке тәртип кагыйдәләре нигезендә билгеләнүче эш сәгатьләрендә шимбә һәм якшәмбедән тыш көн саен.

1.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Министрлыкның иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә, Идарәләрдә (бүлекләрдә) урнашкан, дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль һәм текстлы мәгълүматтан торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларына урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте турында бу Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала.

2) "Интернет" челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның рәсми сайтында – http://mtsz.tatar.ru;

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

"Россия Федерациясендә инвалидларны яклау турында" 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 181-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Персональ мәгълүматлар турында" 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында" 29 декабрь, 2006 ел, № 256-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2007, № 1, 19 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Электрон имза турында" 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында" 28 декабрь, 2013 ел, № 442-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52, 7007 ст.);

"Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында" 7 май, 2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президентының № 601 Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге "Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеген раслау турында" № 831-р әмере (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 20, 2844 ст.);

Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнарны компенсацияләү юлы белән, ана (гаилә) капиталы акчасын (акчаның бер өлешен) андый товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга юллауның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге "Инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга чыгымнарны компенсацияләү юлы белән, ана (гаилә) капиталы акчасын (акчаның бер өлешен) андый товарлар һәм хезмәт

күрсәтүләрне сатып алуга юллау кагыйдәләре турында" № 380 карары белән расланган кагыйдәләре (алга таба – № 380 Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 20, 2828 ст.);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 16 июнендәге "Гражданнарның ана (гаилә) капиталы акчасын, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасына туры китереп, инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алуга файдалану хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итү буенча эшне оештыру турында" № 296 боерыгы (алга таба – № 296 Боерык) (Россия Федерациясенең хезмәт турындагы һәм социаль законнары бюллетене, 2016, № 7);

"Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге кайбер мәсьәләләрне җайга салу турында" 2014 елның 18 декабрендәге № 126-ТРЗ Татарстан Республикасы законы (Татарстанның Дәүләт Советы хәбәрләре, 2014, № 12, 1361 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре" 15.08.2007, № 388 карары ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслауның "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган тәртибе (алга таба – № 880 Тәртип) ("Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы" журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын гражданнарга бирүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 4 октябрендәге "Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын гражданнарга бирү тәртибе турында" № 568 боерыгы белән расланган тәртибе (алга таба – № 568 Тәртип) (Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2016 елның 27 октябре).

1.6. Бу Регламентта "Россия Федерациясендә инвалидларны яклау турында" 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ Федераль закон, "Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында" 2006 елның 29 декабрендәге № 256-ФЗ Федераль закон, "Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон, 2013 елның 28 декабрендәге "Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында"

№ 442-ФЗ Федераль закон билгеләгән мәгънәләрдәге төшенчәләр һәм терминнар, шулай ук түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүмат керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү "тәрәзә"се.

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата (№ 210-ФЗ Федераль законның 2 ст. 1 п.). Гаризаның формасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү атамасы | Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү | № 380 Кагыйдәләрнең 5 п.;<br>№ 568 Тәртипнең 1.1 п. |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) | № 380 Кагыйдәләрнең 6 п.;<br>№ 568 Тәртипнең 1.1 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү акты | № 568 Тәртипнең 3.3 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып; туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Дәүләт хезмәте гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәгән көннән алып биш эш көненнән соңга калмыйча күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылмаган. | № 380 Кагыйдәләрнең 6 п.;<br>№ 568 Тәртипнең 3.2 п. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү турында № 568 Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча гариза.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән гариза бирүче паспортын яки шәхесен таныклаучы башка документын күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның законлы вәкилләре (законнар белән күздә тотылган очракларда) яисә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар тапшыра.<br>Гариза бирүче гаризаны һәм документларны почта элемтәсе оешмалары аша кәгазьдә яисә, “Интернет” мәгълүмат- | № 568 Тәртипнең 2.1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | телекоммуникация челтәреннән файдаланып, “Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон һәм “Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрә ала.<br>Гаризаны почта элемтәсе оешмалары аша җибәргәндә, гаризага кушып, гражданин тарафыннан вәкаләт бирелгән затның яки гражданинның законлы вәкиленең гражданинның мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә расланган күчермәләре бирелә.<br>Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырылган. | |
| 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек каналлары аша мәгълүматлар алу таләп ителми. | |
| 2.7. Норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен аларның килештерүләре (дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы | Килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан башкарыла) таләп ителә торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Гариза бирүче тарафыннан имзаланмаган гариза тапшыру.<br>2. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документны тапшырмау.<br>3. Документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу.<br>4. Гариза бирүченең почта аша яки электрон документлар рәвешендә документларның Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган күчермәләрен җибәрүе.<br>5. Бу Регламентның 1.3 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга яки аннан баш тартуга нигезләр билгеләнмәгән. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать иткәндә, чиратта көтү вакыты 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | № 601 РФ Президенты Указының 1 п. |
| 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатен, | Гариза һәм документлар кергән көнне. | № 568 Тәртипнең 2.2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| шул исәптән электрон рәвештә, теркәү срогы | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына тәңгәл рәвештә, әлеге объектларның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү урыныннан инвалидларның тоткарлыксыз файдалана алуы, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керүе һәм алардан чыгуы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү урынына бару максатыннан, объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиаль мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән аралашулары саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып торалар:<br>Идарә (бүлек) биналарының инвалидлар файдалана алырлык булуы һәм Идарә (бүлек) биналарының җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеп алына торган бүлмәләрнең булуы;<br>мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйләнмәгән, аларның хезмәт күрсәтүләрне башка затлар белән бертигез алуына комачаулаучы башка киртәләрне узуда ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып торалар:<br>документларны кабул итү һәм карап тикшерү сроклары үтәлү; | № 880 Тәртипнең 2.4 п.;<br>№ 601 РФ Президенты Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;<br>Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан бу Регламент бозылу очракларының (нигезле шикаятьләрнең) булу-булмавы;<br>гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән аралашуы саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан-туры – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер тапкыр аралашуының дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп) күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүматны http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/) алырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. | № 210-ФЗ Федераль закон;<br>№ 63-ФЗ Федераль закон |

## 3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын (алга таба – тикшерү акты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен төзү һәм гариза бирүчегә тапшыру;

4) техник хатаны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.

3.1.2. Тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка 2 нче кушымтада бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә

Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Идарәгә (бүлеккә) шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән мөрәҗәгать итә.

Идарә (бүлек) белгече, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Бу пункт билгели торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче, Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар күрсәтеп, тикшерү актын бирү турында гариза бирә.

Гариза һәм документларның Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә расланган кушып бирелүче күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) почта аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон рәвештә җибәрелүче гариза һәм документлар (документлар

күчермәләре) № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә имзалана (раслана) һәм электрон җайланмалардан һәм (яки) гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән (Интернет челтәрен дә кертеп) файдаланып тапшырыла.

3.3.2. Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

законлы вәкил сыйфатында эш итүче гариза бирүченең яисә дәүләт хезмәте алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

кирәкле барлык документларның булу-булмавын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирү-бирмәвен (документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм билгеләнгән тәртиптә расланмаган төзәтүләр булу-булмавын) тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пунктында күздә тотылган нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Гаризаны теркәүдән баш тартуга бу Регламентның 2.8 пунктында күздә тотылган нигезләр булган очракта, Идарә (бүлек) белгече, гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуга нигезләр булу турында хәбәр итә (аларны күрсәтеп) һәм, гариза бирүченең телдән мөрәҗәгате буенча, баш тартуны язмача рәсмиләштерә; гариза һәм документлар почта яки электрон почта аша алынган булса – гаризада күрсәтелгән ысул белән (хат, телефоннан, смс-хәбәр, электрон почта).

Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны кабул итә һәм тикшерү актын бирү турындагы гаризаларны теркәү журналында (алга таба – журнал) (№ 568 Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча алып барыла) терки;

гариза бирүчегә гаризаны һәм документларны теркәү көне, бирелгән керү номеры (гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) күрсәтелгән кабул итү турында расписка яки бирә яки гаризада күрсәтелгән ысул белән (хат, телефоннан, смс-хәбәр, электрон почта), гаризаны теркәү көне, бирелгән керү номеры турында гариза бирүчегә хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедуралар үтәлә:

шәхсән кабул иткәндә – гариза һәм документлар кергән көнне;

гариза һәм документлар почта аша яки гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре (Интернет челтәрен дә кертеп) аша кергәндә – гариза һәм документлар Идарәгә (бүлеккә) кергән көнне яисә, гариза һәм документлар Идарәнең (бүлекнең) эш вакыты тәмамлангач кергән очракта, икенче көнне. Гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял яки эшләми торган бәйрәм көннәрендә кергән очракта – Идарәнең (бүлекнең) ял яки эшләми торган бәйрәм көннән соң килүче беренче эш көнендә.

Процедуралар нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза, журналда теркәү язуы булдыру, гаризаны кабул итү көне һәм аны теркәү номеры турында гариза бирүчегә хәбәр итү яки гаризаны кабул итүдән баш тарту турында гариза бирүчегә телдән (язмача) хәбәр итү һәм гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Идарә (бүлек) белгече түбәндәгеләрне башкара:

Социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре тикшерү актын төзү буенча әзерлек эшләре алып барсын өчен, теркәлгән гаризаның күчермәсен, якланган элемтә каналлары буенча, Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең инвалид бала яшәгән урындагы комплекслы үзәгенә (алга таба – Социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге) тапшыра.

Бу пункт билгели торган процедура гариза теркәлгән көннән алып бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гаризаның Социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә тапшырылган күчермәсе.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен төзү һәм гариза бирүчегә бирү

3.4.1. Социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре:

гаризада күрсәтелгән ысул белән (хат, телефоннан, смс-хәбәр, электрон почта), тикшерү актын төзү һәм бирү өчен, инвалид баланың гаризада күрсәтелгән яшәү урынына гаиләгә килүенең көне һәм вакыты турында гариза бирүчегә хәбәр итә;

тикшерү актын төзү һәм бирү өчен гаиләгә бергәләп бару көне һәм вакыты турында бу Регламентның белешмә-кушымтасында күрсәтелгән телефон һәм электрон почта аша Идарә (бүлек) җитәкчесенә хәбәр итә;

гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар, шулай ук Идарәдән (бүлектән) электрон рәвештә алынган, инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасының гамәлдә булу вакыты турында белешмәләр кергән документлар нигезендә, № 568 Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча тикшерү актын төзү өчен мәгълүмат әзерли;

норматив хокукый актлардан, гомуми кулланылыштагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, шул исәптән “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, гаризада күрсәтелгән товарның тасвирламасы һәм сыйфатламасы кергән мәгълүмат әзерли.

Бу пункт билгели торган процедура гариза Идарәдә (бүлектә) теркәлгән көннән алып ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: тикшерү актын төзү һәм бирү өчен гаиләгә бару көне һәм вакыты турында гариза бирүчегә һәм Идарә (бүлек) җитәкчесенә хәбәр итү, тикшерү актын төзү өчен әзерләнгән мәгълүмат һәм гаризада күрсәтелгән товарның тасвирламасы һәм сыйфатламасы кергән мәгълүмат.

3.4.2. Социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре инвалид баланың гаризада күрсәтелгән яшәү урынындагы Идарә (бүлек) җитәкчесе белән берлектә башкара:

инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең товар сатып алынган көндә гамәлдә булган – “Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медик-социаль экспертиза баш бюросы” ФКУ тарафыннан бирелгән индивидуаль программасында һәм барлыгы тикшерелә торган товарның сатып алу документларында күрсәтелгән товарның барлыгын тикшерә;

инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү нәтиҗәләрен терки һәм ике нөсхәдә № 568 Тәртипнең 3 нче кушымтасы нигезендәге форма

буенча тикшерү актын төзи, нөсхәләр Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан, Социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенең социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге хезмәткәре һәм дәүләт хезмәте алучы тарафыннан имзалана (дәүләт хезмәте алучы яки аның законлы вәкиле әлеге актны имзалаудан баш тарткан очракта, анда бу хакта язып куела).

Тикшерү актының бер нөсхәсе, аны төзегән көнне, Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан, гражданинга Россия Федерациясе Пенсия фондына тапшыру өчен бирелә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү, тикшерү актын төзү һәм бирү.

3.4.3. Идарә (бүлек) белгече:

дәүләт хезмәтенең күрсәтелүе турында журналга язып куя һәм, тикшерү актын бирү турындагы мәгълүматны кертүне күздә тоткан дәүләт мәгълүмат системасы булганда, тикшерү актын бирү турындагы мәгълүматны аңа кертә.

Бу пункт билгели торган процедуралар инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү акты бирелгән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтенең күрсәтелүе турында журналга язып кую, тикшерү актын бирү турындагы мәгълүматны кертүне күздә тоткан дәүләт мәгълүмат системасы булганда, тикшерү актын бирү турындагы мәгълүматны аңа кертү.

3.5. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары аша күрсәтелми.

3.6. Техник хатаны төзәтү

Тикшерү актын төзәтү элек бирелгән актта җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата) бетерүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Тикшерү актындагы техник хаталарны төзәтү, элегрәк бирелгән – техник хатасы булган тикшерү актын кушып, техник хатаны төзәтү турында Идарәгә (бүлеккә) бирелгән гариза нигезендә башкарыла.

3.6.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм журналда терки, “Гаризаны теркәү көне һәм вакыты” графасында “техник хатаны төзәтү” дип өстәп язып куя.

Тикшерү актының элегрәк төзелгән ике нөсхәсендәге техник хатаны төзәтә, бу вакытта бетерүләр һәм төзәтү чаралары ярдәмендә төзәтүләр рөхсәт ителми;

ике нөсхәдә төзәтелгән тикшерү актын, аларга кертелгән төзәтүләрне раслау өчен, Идарә (бүлек) җитәкчесенә тапшыра;

тикшерү актын бирү турындагы мәгълүматны кертүне күздә тоткан дәүләт мәгълүмат системасы булганда, тикшерү актында төзәтелгән мәгълүматны аңа кертә.

Бу пункт билгели торган процедура техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көннән алып бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, төзәтелгән һәм Идарә (бүлек) җитәкчесенә раслау өчен тапшырылган тикшерү акты.

3.6.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе:

"төзәтелгәненә ышанырга" дип язып, Идарә (бүлек) мөһерен басып, тикшерү актындагы төзәтүләрне ике нөсхәдә үз имзасы белән раслый;

ике нөсхәдә расланган төзәтелгән тикшерү актын Идарә (бүлек) белгеченә тапшыра.

Бу пункт билгели торган процедура тикшерү актындагы техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көннән алып бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм расланган, Идарә (бүлек) белгеченә тапшырылган тикшерү акты.

3.6.3. Идарә (бүлек) белгече:

дәүләт хезмәте алучының (дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиленең) төзәтелгән тикшерү актын алуының техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысулына бәйле рәвештә, төзәтелгән тикшерү актын дәүләт хезмәте алучыга (дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиленә) почта белән җибәрә яки, элегрәк бирелгән тикшерү актындагы техник хатаның төзәтелүе турында аңа мәгълүмат биреп, техник хатаны төзәтү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (телефоннан, смс-хәбәр, электрон почта белән) аны төзәтелгән тикшерү актын Идарәдән (бүлектән) алу өчен чакыра;

журналга язып куя.

Бу пункт билгели торган процедуралар төзәтелгән тикшерү акты расланган һәм имзаланган көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте алучыга (дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиленә) төзәтелгән тикшерү актын җибәрү яки тапшыру, журналдагы язма.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә агымдагы контрольлек, бу Регламент нигезләмәләрен саклауга һәм үтәүгә тикшерүләр үткәрү юлы белән, Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

4.2. Идарә (бүлек) вазыйфаи затларының дәүләт хезмәте күрсәтүенә контрольлек итүне Министрлыкның вазыйфаи затлары башкара. Контрольлек итүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык бүлекләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлүенә контрольлек формалары булып, тикшерү үткәрү тора:

делопроизводствоны алып баруны;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнар (бу Регламент) таләпләренә туры килүен;

документларны кабул итү сроклары һәм тәртибе үтәлүне;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләрне бирү сроклары һәм тәртибе үтәлүне.

Тикшерүләр уздыруның ешлыгы планлы (эш планнары нигезендә башкарыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.3. Гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта, уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсе буенча, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контрольлек итү Идарә (бүлек) эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерелү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр тәртиптә Идарә (бүлек) җитәкчесенә шикаять белдерүгә хокуклы.

Идарә (бүлек) җитәкчесенең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның шуның өчен җаваплы урынбасары яки министр исеменә бирелә.

Министр урынбасары (министр) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә, һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан яисә җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерү очрагында яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерү очрагында – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган: дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның – фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүченең атамасы, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән вакыйгаларны раслаучы документлар күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тапшырган дәүләт хезмәте алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бу Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаны гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Бу пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм гариза бирүченең теләге буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

*Форма*

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

__________________________________________

(муниципаль районндагы (шәһәр округындагы)

Социаль яклау идарәсе (бүлеге)

## Инвалид бала өчен сатып алынган товарның[1] барлыгын тикшерү актын бирү турында гариза

____________________________________________________________________

(ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

____________________________________________________________________

(ана (гаилә) капиталына дәүләт сертификаты хуҗасының законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда))

1. Гариза бирүченең – сертификат хуҗасының/аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документ (кирәклесенең астына сызарга)

____________________________________________________________________

(документның атамасы, номеры һәм сериясе, кем тарафыннан һәм кайчан бирелүе)

____________________________________________________________________

2. Инвалид бала турында мәгълүматлар ________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме,

____________________________________________________________________

туган көне, ае, елы)

3. Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасының номерын һәм көнен күрсәтеп, сатып алынган товарның атамасы: ________________________

____________________________________________________________________

4. Гариза бирүченең элемтәгә керү өчен телефоны һәм инвалид баланың яшәү урыны адресы:

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

5. Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү өчен гаиләгә килү көне һәм вакыты турында мәгълүматны алырга риза: ________________________________

(язмача, телефоннан, смс-хәбәр итеп, электрон почта аша)

(кирәклесенең астына сызарга һәм күрсәтергә)

| | |
|---|---|
| "___" ___________ 20___ ел | ____________ __________________<br>(имза) (тулы имза Фамилия, инициаллар) |

[1] Товар инвалид балаларны социаль яраклаштыру һәм җәмгыятькә кертеп җибәрү өчен билгеләнгән.


\- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

(кисеп алу сызыгы) Расписка-хәбәрнамә

| | |
|---|---|
| Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү турында гариза кабул ителде һәм теркәлде: № _______<br>"____" ____________ 20 ____ ел. | Кабул итте:<br>__________ ____________________<br>(белгеч имзасы) (хезмәткәрнең ФИО, телефоны) |

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы**



СХККҮ хезмәткәре (социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге):
гаиләгә килүнең көне һәм вакыты турында гариза бирүчегә, Идарә (бүлек) җитәкчесенә хәбәр итә;
тикшерү актын төзү өчен мәгълүмат әзерли;
гаризада күрсәтелгән товар турында мәгълүмат әзерли – 2 эш көне

СХККҮ хезмәткәре (социаль хезмәтне өйдә күрсәтү бүлеге) Идарә (бүлек) җитәкчесе белән бергәләп:
тикшерү актын төзи;
товарның барлыгын тикшерү нәтиҗәләрен форма буенча актта теркәп куя;
тикшерү актын имзалый – акт төзелгән көнне (гаризаны теркәү көненнән алып 5 эш көненнән соңга калмыйча)

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерүнең төзелгән һәм бирелгән акты

Гариза бирүчедән техник хатаны төзәтү турында гариза кергән очракта, Идарә (бүлек) белгече тикшерү актын төзәтә – 1 эш көне

Төзәтелгән тикшерү акты

Идарә (бүлек) җитәкчесе төзәтелгән тикшерү актын раслый һәм имзалый – 1 эш көне

Расланган һәм имзаланган төзәтелгән тикшерү акты

Идарә (бүлек) белгече гариза бирүчегә төзәтелгән тикшерү актын җибәрә/тапшыра – 1 эш көне

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерүнең төзәтелгән һәм имзаланган акты

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

*Форма*

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

______________________________________

(муниципаль районындагы (шәһәр округындагы)
Социаль яклау идарәсе (бүлеге)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ________________________________________________,
*(дәүләт хезмәте алучының (дәүләт хезмәте алучының законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*
түбәндәге адрес буенча яшим: ______________________________
____________________________________________________
*(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адресы)*
____________________________________________________
*(гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирү көне,*
____________________________________________________,
*документны биргән орган атамасы)*

бу гаризага кушымта итеп бирелүче, инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актында __________________ № ____________ җибәрелгән
*(тикшерү актын бирү көне)* *(актның номеры)*
техник хатаны ____________________________________________
____________________________________________ төзәтүне үтенәм.

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерүнең элегрәк бирелгән актындагы техник хатаның төзәтелүе турында мәгълүматны алырга риза: турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны бирү карары хакындагы мәгълүматны алырга риза:

____________________________________________________
(телефоннан, смс-хәбәр, электрон почта белән)
(кирәклесенең астына сызарга һәм күрсәтергә)

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерүнең төзәтелгән актын алырга риза: ______________________________________
(шәхсән яисә почта белән)
(кирәклесен күрсәтергә)

"__" ________ 20__ ел                    ______________ ________________________
(гариза бирүче имзасы) (тулы имза: фамилия, инициаллар)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

(кисеп алу сызыгы) Расписка-хәбәрнамә

| | |
|---|---|
| Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актындагы техник хатаны төзәтү турында гариза кабул ителде һәм теркәлде:<br>№ _______<br>"____" __________ 20 ___ ел. | Кабул итте:<br>__________ ________________________<br>(белгеч имзасы) (хезмәткәрнең ФИО, телефоны) |

Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

**Инвалид бала өчен сатып алынган товарның барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85551) 2-10-86 2-11-53 | 422230, Әгерҗе ш., К.Маркс ур., 8 й. Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85592) 7-25-10 7-14-25 | 423330, Азнакай ш., Болгар ур., 9 й. Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84344) 2-92-74 2-92-72 | 423060, Аксубай ш.т.б., Мазилин ур., 2 й. Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85552) 3-11-46 3-12-81 | 423740, Актаныш ав., Юбилей ур., 45 й. Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84341) 2-41-40 2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.б., Казаков ур., 8 й. Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84346) 2-08-90 2-08-80 | 422870, Базарлы Матак ав., Ленин ур., 9 й. Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (8553) 32-45-50 32-45-43 | 423452, Әлмәт ш., К.Цеткин, 54а й. Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84376) 2-11-84 2-10-81 | 422350, Апас ав., Шоссе ур., 5 й. Usz.Apastovo@tatar.ru |

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Арча муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | 422000, Арча ш.,<br>Банк ур., 6в й.<br>Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84369)<br>2-16-60<br>2-10-84 | 422750, Олы Әтнә ав.,<br>Октябрь ур., 9 й.<br>Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, Баулы ш.,<br>Җиңү мәйданы, 4 й.<br>usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84368)<br>2-44-78 | 422250, Балтач ав.,<br>һ.Такташ ур., 3а й.<br>Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85594)<br>6-55-70<br>4-26-64 | 423230, Бөгелмә ш.,<br>Стрелочная ур., 1 й.<br>Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84374)<br>3-32-10<br>3-35-35 | 422430, Буа ш.,<br>Ленин ур., 52 й.<br>Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84379)<br>2-17-57<br>2-22-76 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медгородок ур.<br>Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84365)<br>2-32-43<br>2-32-50 | 422700, Биектау т/ю ст. б.,<br>Профсоюзлар ур., 1а й.<br>Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84375)<br>2-38-07<br>2-31-52 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й.<br>Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85557)<br>7-86-91<br>7-87-86 | 423600, Алабуга ш.,<br>Спас ур., 3 й.;<br>Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85558)<br>7-09-76<br>7-10-64 | 423520, Зәй ш.,<br>Рафиков ур, 10 й.<br>Usz.Zainsk@tatar.ru |

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Зеленодол муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84371)<br>5-58-80<br>4-22-97 | 420540, Зеленодол ш.,<br>Карл Маркс ур., 57В й.<br>Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-15-57<br>2-11-12 | 422330, Олы Кайбыч ав.,<br>Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-45 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б.,<br>Карл Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.б.,<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.т.б., Беренче Май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Гагарин ур., 51 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36<br>3-19-69 | 422190, Мамадыш ш.,<br>Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеев муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00 | 423650, Менделеев ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-77<br>3-14-52 | 423700, Минзәлә ш.,<br>Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37<br>2-57-69 | 423970, Мөслим ав.,<br>Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегендәге Социаль яклау идарәсе | (8552)<br>34-48-48<br>58-71-52 | 423805, Чаллы ш.,<br>проспект Х.Туфана, д. 23<br>Usz.Chelny@tatar.ru |

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Түбән Кама муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89 | 423570, Түбән Кама ш.,<br>Тынычлык пр., 60 й.<br>usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84348)<br>2-20-15<br>2-27-91 | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-55 | 423042, Нурлат ш.,<br>Пушкин., 46 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84367)<br>3-06-68<br>3-06-72 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | 422650, Балык Бистәсе ав.,<br>Завод ур., 6а й.<br>Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84362)<br>2-28-55<br>2-28-11 | 422060, Байлар Сабасы ав.,<br>Закир Йосыпов ур., 7 й.<br>Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85559)<br>2-45-72<br>2-49-87 | 423350, Сарман ав.,<br>Куйбышев ур., 36 й.<br>Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84347)<br>3-08-81<br>3-08-98 | 422864, Болгар ш.,<br>Пионерлар ур., 21 й.<br>Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-09<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш ш.,<br>Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57<br>70-13-41 | 423807, Чаллы ш., Есенин тыкр., 1 й.<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84360)<br>2-13-41 | 422080, Теләче ав.,<br>Большая Нагорная ур., 5 й.<br>Usz.Tulachi@tatar.ru |

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Чирмешән муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-50-94 | 423100, Чирмешән ав., Титов ур, 26 й.<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84342)<br>5-55-73<br>5-11-50 | 422980, Чистай ш., Урицкий ур., 45 й.<br>Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-21-43<br>2-82-91 | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 105/1 й.<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Социаль яклау бүлеге | (843)<br>571-58-00<br>510-31-15 | 420036, Казан ш., Тимирязев ур., 8 й.<br>Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Вахитов районындагы Социаль яклау бүлеге | (843)<br>238-10-55<br>238-41-91 | 420197, Казан ш., Вишневский ур., 10 й.<br>Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров районындагы Социаль яклау бүлеге | (843)<br>554-47-80<br>554-29-41 | 420102, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5 й.;<br>Usz. Kirov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Мәскәү районындагы Социаль яклау бүлеге | (843)<br>554-02-16<br>564-81-63 | 420102, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5 й.;<br>Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Яңа Савин районындагы Социаль яклау бүлеге | (843)<br>523-75-92<br>523-75-82 | 420124, Казан ш., Хөсәен Ямашев проспекты, 37 й.<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |

| Территориаль орган атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Идел буе районындагы Социаль яклау бүлеге | (843) 224-04-20 224-11-14 | 420110, Казан ш., Рихард Зорге ур., 39 й. Osz.Priv@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районындагы Социаль яклау бүлеге | (843) 273-18-06 272-51-79 | 420073, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 33 й.; Msz.SovOR@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 557-20-02 | mtsz@tatarstan.ru |
| Министр урынбасары | (843) 557-20-07, 557-20-03 | mtsz@tatarstan.ru |
| Инвалидлар белән эшләү бүлеге начальнигы | (843) 557-21-55 | mtsz@tatarstan.ru |
| Социаль хезмәт күрсәтү методологиясе бүлеге начальнигы | (843) 557-20-57 | mtsz@tatarstan.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты аппаратының Социаль үсеш идарәсе начальнигы | (843) 264-77-29 | pisma@tatar.ru |